Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Пычак авыл җирлеге
Советы

КАРАР

«03» августа , 2026 ел №10

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Советының 2024 елның 10 июнендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Кукмара районы прокурорының 2026 елның 22 июнендәге 02-08-01 номерлы протестын карап, Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Советының 2024 елның 10 июнендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә (2025 елның 15 апрелендәге 8 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.9. пунктының беренче абзацында «видео-конференц-элемтә,» сүзеннән соң «Инспектор» «мобиль кушымтасыннан файдалану,» сүзләрен өстәргә;

1.2. 3.11 пунктының дүртенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Контрольдә тотылучы затка мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында, башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә хәбәр ителә.».

Җирлек башлыгы: Г.Ш.Нафиков